КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 27 ноябрь г.Казань № 1067

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә конкуренцияне үстерү чаралары турында» 2010 ел, 9 апрель, 251 нче карарына 3 нче кушымтага үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә конкуренцияне үстерү чаралары турында» 2010 ел, 9 апрель, 251 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 27 июнь, 441 нче; 2015 ел, 19 май, 357 нче; 2017 ел, 7 август, 560 нчы; 2019 ел, 2 сентябрь, 757 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) теркәлгән 3 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 нче пунктының 3.3.9 нчы пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.9. Милекчегә (яисә аның вәкиленә) финанс-хуҗалык эшчәнлегенең төп күрсәткечләре, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау буенча күрсәтелә торган хезмәтләр һәм башкарыла торган эшләр турындагы, аларны күрсәтү һәм башкару тәртибе һәм шартлары турындагы, аларның кыйммәте, күрсәтелә торган коммуналь хезмәтләргә бәяләр (тарифлар) турындагы мәгълүматтан аларны торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – ТКХ дәүләт мәгълүмат системасы) урнаштыру юлы белән ирекле файдалану мөмкинлеген тәэмин итәргә.»;

4.1.5 нче пунктның 4.1.5 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.5. Финанс-хуҗалык эшчәнлегенең төп күрсәткечләре, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау буенча күрсәтелә торган хезмәтләр һәм башкарыла торган эшләр турындагы, аларны күрсәтү һәм башкару тәртибе һәм шартлары турындагы, аларның кыйммәте, күрсәтелә торган коммуналь хезмәтләргә бәяләр (тарифлар) турындагы мәгълүматтан ирекле файдалана алырга.»;

7.5 нче пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Идарә итүче оешма тарафыннан финанс-хуҗалык эшчәнлегенең төп күрсәткечләре, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау буенча күрсәтелә торган хезмәтләр һәм башкарыла торган эшләр турындагы, аларны күрсәтү һәм башкару тәртибе һәм шартлары турындагы, аларның кыйммәте, күрсәтелә торган коммуналь хезмәтләргә бәяләр (тарифлар) турындагы мәгълүматны ТКХ дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыру юлы белән ачу;»;

Бүлмә милекчесе белән күпфатирлы йорт белән идарә итү шартнамәсенә 2 кушымтаның 17 нче пунктындагы «Коммуналь хезмәт күрсәтү исеме» графасына «урыннар» сүзеннән соң «(мәйданчыклар)» сүзен өстәргә;

Бүлмә милекчесе белән күпфатирлы йорт белән идарә итү шартнамәсенә 4 нче кушымтада:

1 бүлектә:

3 нче пунктның 3.2 нче пунктчасында «һәм күпфатирлы йортның гомуми мөлкәте территориясендә урнашкан контейнер мәйданчыкларын җыештыру» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 нче пунктта:

беренче абзацка «урыннар» сүзеннән соң «(мәйданчыклар)» сүзен өстәргә;

5.1 нче пунктчага «урыннар» сүзеннән соң «(мәйданчыклар)» сүзен өстәргә;

2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле $91^1$ нче пункт өстәргә:

«$91^1$. Күпфатирлы йортның гомуми мөлкәтенә караган урыннарда урнаштырылган электр энергиясен исәпкә алуның күмәк (гомумйорт) приборларының, шулай ук электр энергиясен (егәрлекне) исәпкә алуның интеллектуаль системасына керә торган башка җиһазның сакланышын тәэмин итү.»;

Бүлмә милекчесе белән күпфатирлы йорт белән идарә итү шартнамәсенә 8 нче кушымтаның 8 нче пунктындагы өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Идарә итүче оешма финанс-хуҗалык эшчәнлегенең төп күрсәткечләре, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау буенча күрсәтелә торган хезмәтләр һәм башкарыла торган эшләр турындагы, аларны күрсәтү һәм башкару тәртибе һәм шартлары турындагы, аларның кыйммәте, күрсәтелә торган коммуналь хезмәтләргә бәяләр (тарифлар) турындагы мәгълүматны ТКХ дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыру;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин